# Фәния Латыйпова (Кәримова): Сугыш чорындагы онытылмас бала чагыбыз.

Без бер очта яши торган 6-7 бала, барыбызның да әтәйләре сугышта. Без яшәгән урында инеш якын, челтәр-челтәр тезлеп киткән чирәмле, җиләкле тау башлары, тирән, озын Кәбеләй яры.. Без туйганчы урамда уйныйбыз, аннан Бикә әби тавына барып туйганчы песәй борчагы ашыйбыз, Олы чишмә янындагы буалган инеш суында су керәбез, йөзәргә өйрәнәбез. Алиса үзенә дә, миңа да мендәр тышы алып килә, суга салсаң ул шар кебек кабара, тотып йөзәсең. Чыгабыз судан, китәбез тау башына, анда җиләк чәчәген генә койган була, без шул бөрене, чыпчык кузгалагын ашыйбыз. Без бит әтәйләр турында бер сүз дә сөйләшмәдек, безнеңчә, булмаганнарда кебек. Әтәйләр турында әнәйләр дә сүз чыгармады, үсеп җитеп сораштыра башламаенчы. Без бит әнәй ашасым килә дип елап, сорап утырмадык. Уенга мавыктык... Әле минем Шарифҗаным да бар бит. Өйдә дә кызлар гына, ә Шарифҗан “Мин кыз кеше”-ди. “Исемем – Маргүрә” – кесәле, пояслы күлмәк сорый. Оркыя апабыз Мәхмүтова аңа гимнастёркага ошатып күлмәк тегә, түшендә кечкенә ике кесә, поясы тегелгән, пояс астында ике зур кесә. Бу үзен кыз кеше итте. Нинди чүпрәк – чапрак әйберләр бар, агач чиләккә тутыра да, кер юарга төшеп китә. Кайта сөйрәп комга аунатып: “Үзем юдым” – ди. Әнәй, Хадичә апа эштә, безне күрүче юк. Без дөньяны онытмыйбыз, Хадичә апа кузгалак алып кайта, котомка белән чистартып пучоклар эшләргә кирәк, чөнки апа базарга сатарга барачак.

Кызларның әбиләре, апалар безгә бәрәңге алып бирәләр дә, тагын инеш буена әрчеп юарга төшәбез. Буа читәннән үреп ясалган, читән арасыннан җылы су ага. Җыелышып комган, самовар, табак-савытларны ком белән ышкып ялтыратабыз, кояшта киптерәбез. Ялык-йолык килә инде. Балалар гына булсак та уйнарга да, юк-бар эш эшләргә дә булыштык. Без бервакытта да урлашмадык, сугышмадык, көнләшмәдек, начар сүзләр сөйләшмәдек. Югыйсә, без бит урамда үткәрдек күп вакытны...

Базар көнне әнәйләрне каршы алырга бардык зират чокырына.

Шиабиева Сәлимә 41 нче елгы, Махмутова Алисә 40 нчы елгы, мин – 39 нчы елгы, Исламова Нәсимә 39 нчы елгы, Минәчева Саймә 39 нчы елгы, Шайгалламова Вафирә 38 нче елгы, Закирова Фәһимә 38 нче елгы.

Нәсимә белән мин генә 4 балалы. Нәсимәнең Мөнҗия апасы сукыр булса да бияләй, оекбашлар бәйләй торган иде. Әниләре 50-51нче елларда озак чирләп ятып үлеп китте, 1-2 елдан Мәндүдә апасы әнисе кебек үк чирләп үлде, шул көннәрдә Мөнҗия апасы Иж елгасына катмаган урынга эләгеп иптәш кызы белән батып үлгәннәр (сукырлар йортында иде). Озак та үтмәде, Мәймүнә апасы Нәсимә белән Свердловскийга Мәрьям апалары (ике туган) янына киттеләр. Хат алышып, кунакка кайта торган иде. 17-18 яшьләрендә шул ук чир белән үлеп китте.

Җәйләр үтте, кыш җитте. Кыш көне Бикә әби тавына шуарга барабыз. Чана Алисәнеке генә бар, бер үзе генә сыя торган – кошовка. Ә без, чана юк дип аптырап тормайбыз. Бикә әбинең бик текә бер ярына тирес түгәләр, шул тирес арасыннан сыер ятып йоклаган зур тизәкне сайлыйбыз да, шуның белән шуабыз. Кыш буена аның асты ялтырап тора. Ә менә Алисәнеке “худлы”рак, чана бит көннәрдән бер көнне су ала торган бәкегә кадәр шуып, бәкегә чумган. Тизрәк кайттык, безгә әнәй итек, пальтосын мичкә киптерергә куйгандыр инде, ә без мич башында утырдык. Чыккач ачуландылармы, юкмы, сорашмадык.

Безнең әнәйләр сыер җигеп печән, утын, салам ташыды. Тиресне колхоз кырларына түктеләр. Ә Вафирәнең апасы ат карауччы булып эшләде, киресенчә, ул

дубырдан (ат абзарын бездә шулай диләр) тирес алып кайта иде. Без Нәсимә белән Гайшәтәйнең тыкырыктан күренүе белән Вафирәләргә кереп зур сәкегә менеп утырабыз. Өйләре җылы, тәмле исләр генә килә, төш вакыты бит. Менә тиресне читән аша бакчага атып, тирес астындагы печәнне малларга салып Гайшәтәй өйгә керә. Ул ирләргә ошап тора: шундый зур гәүдәле, бер күзе аклы, ирләр кебек киенә, башын бераз бер якка ташлап елмая. "Бу сандугачлар тагын монда" – дип уйлый инде. Әсхәб әби зур самоварны өстәлгә китертеп утырта, ипи кисә (алар гел ипи пешерде). Гайшәтәй юынып чыгып өстәл арасына утыруга, Әсхәб әби мичкә салган бәрәңге китертеп утырта. Иң беренче, берәр бәрәңге безгә ата. Зур, аның тәмлелеген Нәсимә белән мин генә беләбез. Вафирә дүрт бармак зурлыгы ипи китереп бирә. Без бәрәңгене конфет суыргандай суырып ашайбыз.

Менә шулай кыш чыкканчы кабатланды. Урыннары оҗмах түрендә булсын!

Тирес турында мин бакча тота башлагач белдем. Иң уңдырышлы ашлама булган икән ул. Шуңа күрә аларның бәрәңгесе эре, күп булган. Менә шулай кыш җәйне, җәй кышны алмаштырып торды. Без дә сау-сәламәт үсәбез. Кул астына керә башладык, уеннарны эшкә алмаштырабыз. Яңа онытылмас тормышлар башланды, яшьтәш кызларны мин апа кебек кызларга алмаштырдым. Ул көннәр турында телисез икән икенче хатымда дәвам итәрмен. Алла теләсә!..

Минем хатымны укучыларыма, авылдашларыма, сайт алып баручыларга бетмәс бәхетләр, чиксез уңышлар, кайгысыз көннәр чын күңелемнән теләп калам.

Фәния Латыйпова (Кәримова)

Красноярский край, Железногорск шәһәре

(Красноярск – 26)

Август, 2020 ел.

*Бу материалны сайтка куярга Фәния апаның туганы Сөмбел Мозафарова эшкәртте*



Исламова Нәсимә



*Минем дустым Мәхмүтова Алиса белән,*
*1951 ел. Миндә Альтаның күлмәге*



Дустым Фәһимә. 1957 ел



*Дустым Вафира белән. 1957 ел*


Сулдан уңга: Мәүҗит Насыйров,
Рәфинәт Шәймөхәмәтов.
Басып тора Шәрифҗан Кәримов